**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 12 » ноябрь 2020 с. Тюлячи № 493

Теләче муниципаль районында 2021 елга балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм мәдәният юнәлешендәге мәгариф оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле белем бирү оешмаларының өстәмә белем бирү программасын тормышка ашыру өчен норматив чыгымнарны раслау турында

ДБУ «Татарстан Республикасы икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге»нең 2020 елның 15 октябрендәге 01/1796 номерлы хатын карап, «Мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 31 декабрендәге 939 номерлы «Татарстан Республикасы балаларына өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрен туристлык- туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм мәдәни юнәлешле һәм күппрофильле мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2021 елга расларга:

- туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм мәдәни юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында һәм Теләче муниципаль районы балаларына өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга кушымтада бирелә торган норматив чыгымнар, кушымта нигезендә;

- балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында туристик-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик,

социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм мәдәни юнәлешле мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирүнеңкүппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарга карата төзәтмәләр коэффициенты 0,5 күләмендә.

2. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының Финанс-бюджет палатасына (Р.Р. Яхин) тәэмин итәргә:

- әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә балаларга өстәмә белем бирү оешмаларын финанслау;

- әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары гамәлдә булган чор дәвамында, хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә башкарыла торган Балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын индексацияләү белән бергә, яңадан карау.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә һәм 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«12» 11 2020 № 493
карарына кушымта

Теләче муниципаль районында балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм мәдәният юнәлешендәге мәгариф оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле белем бирү оешмаларының өстәмә белем бирү программасын тормышка ашыру өчен норматив чыгымнары

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль урнашу | 1 укучыга бер елга норматив чыгымнар, сумнарда | | |
|---|---|---|---|---|
| | | беренче уку елы | икенче ел укыту | өченче һәм аннан соңгы елларда уку |
| Сәнгать-эстетик | авыл җирлеге | 5 970 | 11 055 | 13 266 |
| Физкультура-спорт | авыл җирлеге | 5 868 | 10 867 | 13 041 |
| Техник иҗат | авыл җирлеге | 6 273 | 11 617 | 13 940 |
| Туризм-туган якны өйрәнү | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Экология-биология | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Хәрби-патриотик | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Социаль-педагогик | авыл җирлеге | 5 666 | 10 493 | 12 591 |
| Социаль-икътисадый | авыл җирлеге | 5 666 | 10 493 | 12 591 |
| Табигый | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |

Эшләр идарәчесе И.Т. Һадиев